354

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

23.04.2020

№ 351

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү Тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү Тәртибен, әлеге карарга 1 нче кушымтада бәян ителгән нигезендә расларга.

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү турында» 2019 елның 4 сентябрендәге 1344 карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш һәм рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә алам.

Җитәкче Р. М. Нуриев

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
"354" 23.04.2020 ел
карарына нче кушымта

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык түләүне стимуллаштыру өстәмәсе Алабуга муниципаль районы (алга таба - район) бюджетыннан ай саен бирү механизмын билгели.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә, әмма аена 1 111 сумнан да артык булмаган, айлык стимуллаштыру өстәмәсе түләргә.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының баш бүлүчесе - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты.

4. Айлык стимуллаштыру өстәмәсе педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә бирелә һәм максатчан характер йөртә, башка максатларда файдаланыла алмый.

5. Айлык стимуллаштыру өстәмәсе Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына тиешле финанс елына җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

6. Айлык стимуллаштыру өстәмәсен алу өчен Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты агымдагы елның 1 февраленә кадәр тармак министрлыгына түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган, муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык саен өстәмә түләүләр бирү Тәртибе;

расланган рәвештә башка бюджетара трансфертлар бирелүе турында гариза;

район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында, гаризаны имзалаган затның, вәкаләтләрен раслый торган документ;

Алабуга муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләр - яшь белгечләрнең расланган реестрлары;

муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - педагогик хезмәткәрләргә айлык стимуллаштыру өстәмәсен түләү өчен район бюджетында акча булуын раслаучы документ.

7. Айлык стимул өстәмәсе Тармак министрлыклары һәм Алабуга муниципаль районының башкарма комитеты арасында төзелгән килешү нигезендә бирелә.

8. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты Тармак министрлыкларына хисап кварталыннан соң килүче айның 20 числосына кадәр педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне стимуллаштыручы яшь белгечләргә әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге форма (рәвеш) буенча хисап тапшыра.

9. Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына файдаланылмыйча калган акчалар Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

10. Максатчан файдалануны тикшереп торуны законнар нигезендә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (килешү буенча) гамәлгә ашыра.